ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.12, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Совет мәйданы, 12 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-00-44, факс (84366)3-11-44. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**КАРАР**

«09» сентября 2024 ел　　　　　№ 633

**Махсус хәрби операциядә катнашучы гражданнарның гаиләләренә (гаилә әгъзаларына) өстәмә ярдәм чарасы күрсәтү турында**

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 86 статьясының 1, 2 пунктлары, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясы, 20 статьясының 5 өлешенең икенче абзацы, 43 статьясы нигезендә Арча муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Махсус хәрби операциядә катнашучы Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнар, хәрби хезмәткәрләр һәм Россия Федерациясе Милли гвардиясендә хезмәт итүче затлар, Татарстан Республикасында төзелгән "Алга" һәм "Тимер" батальоннарында хәрби хезмәт узучы гражданнар, махсус хәрби операция барышында хәрби бурычларны ирекле үтәүче гражданнарның гаиләләренә (гаилә әгъзаларына), шулай ук «Россия Федерациясендә өлешчә мобилизация игълан итү турында» 2022 елның 21 сентябрендәге 647 номерлы Россия Федерациясе Президенты Указы нигезендә махсус хәрби операциядә катнашу нәтиҗәсендә һәлак булган (вафат булган) югарыда күрсәтелгән категория гражданнарның гаиләләренә (гаилә әгъзаларына), аны илтеп җиткерүне дә кертеп, каты ягулык ((утын пүләннәре рәвешендә киселгән утын) белән тәэмин итү рәвешендә өстәмә ярдәм чарарсы билгеләргә.

2. Күрсәтелгән ярдәм чарасы әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән затларга елга бер тапкыр күрсәтелә.

3. Әлеге карарның 1 пунктында каралган өстәмә ярдәм чарасын күрсәтү тәртибен 1 нче кушымта нигезендә расларга.

4. Кушымтада бирелгән тәртип нигезендә махсус хәрби операциядә катнашучыларның гаилә әгъзаларына каты ягулык (утын пүләннәре рәвешендә киселгән утын) белән тәэмин итү рәвешендә, аны илтеп җиткерүне дә кертеп, өстәмә ярдәм күрсәтү тәртибе нигезендә, махсус хәрби операциядә катнашучыларның гаилә әгъзаларын каты ягулык белән тәэмин итүгә һәм илтүгә бәйле күрсәтелгән өстәмә ярдәм чарасын гамәлгә ашыру өчен җаваплы итеп Башкарма комитет аппаратының инфраструктура үсеше бүлеге торак-коммуналь хуҗалык, энергетика һәм элемтә секторын билгеләргә.

5. «ТР Арча муниципаль районының финанс-бюджет палатасы» МКУнә (С.П. Галимова) әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән өстәмә ярдәм чарасын гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанслауны тәэмин итәргә.

6. Карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

7. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru/) бастырып чыгарырга һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында (http://arsk.tatarstan.ru/) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

8. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Э.Ш. Вафинага йөкләргә.

Башкарма комитет җитәкчесе Р.М. Гатиятов

Татарстан Республикасы Арча
муниципаль районы Башкарма
комитетының
09.09.2024 ел, №633
карарына 1 нче кушымта

**Махсус хәрби операциядә катнашучыларның гаилә әгъзаларын каты ягулык (утын пүләннәре рәвешендә киселгән утын) белән тәэмин итү рәвешендә, аны илтеп җиткерүне дә кертеп, өстәмә ярдәм күрсәтү тәртибе**

1. Әлеге тәртип махсус хәрби операциядә катнашучыларның гаилә әгъзаларына каты ягулык (утын пүләннәре рәвешендә киселгән утын) белән тәэмин итү рәвешендә, аны илтүне дә кертеп, өстәмә ярдәм чарасын күрсәтү шартларын һәм күләмен билгели.

2. Каты ягулык (утын пүләннәре рәвешендә бүленгән утын) бары тик мич белән генә җылытыла торган (алга таба – мич белән җылыту), шул исәптән утын белән эшли торган автоном җылыту системалы бер бүлмәгә 3 (өч) куб.метр күләмендә бирелә.

3. Махсус хәрби операциядә катнашучыларның гаилә әгъзаларын каты ягулык (утын пүләннәре рәвешендә киселгән утын) белән тәэмин итү һәм аларны илтү чараларын оештыру белән Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитеты аппаратының инфраструктура үсеше бүлегенең торак - коммуналь хуҗалык, энергетика һәм элемтә секторы (алга таба-Сектор) шөгыльләнә.

4. Каты ягулык (утын пүләннәре рәвешендә киселгән утын) белән тәэмин итүгә һәм илтүгә бәйле өстәмә ярдәм чарасы күрсәтелә торган махсус хәрби операциядә катнашучының гаилә әгъзалары дигәндә түбәндәге затлар аңлашыла (алга таба-гаилә әгъзалары):

махсус хәрби операциядә катнашучының яшәү яисә булу урыны буенча теркәлгән хатыны (ире) һәм (яисә) аның балигъ булмаган балалары;

махсус хәрби операциядә катнашучының атасы яки анасы (ата-анасы).

5. Әлеге Тәртипнең 4 бүлегендә күрсәтелгән гаилә әгъзаларын каты ягулык (утын пүләннәре рәвешендә киселгән утын) белән тәэмин итүгә һәм илтүгә бәйле өстәмә ярдәм күрсәтү мөрәгариза бирү характерында була.

6. Каты ягулык (утын пүләннәре рәвешендә киселгән утын) белән тәэмин итүгә һәм илтүгә бәйле өстәмә ярдәм чарасын алу максатыннан, әлеге Тәртипнең 4 бүлегендә күрсәтелгән гаилә әгъзасы Секторга әлеге Тәртипкә 1 нче кушымтадагы форма буенча түбәндәге документлар белән бергә гариза (алга таба – гариза) тапшыра:

мөрәҗәгать итүченең шәхесен таныклаучы документ;

махсус хәрби операциядә катнашучының статусын раслый торган документ;

гаилә әгъзасының һәм махсус хәрби операциядә катнашучының туганлыгын (үзлеген) раслый торган документ (туу (уллыкка алу) турында таныклык, никахлашу турында таныклык, туганлыкны (үзлеген) раслый торган башка документ);

мич белән җылыту турында мәгълүматны үз эченә алган документ;

махсус хәрби операциядә катнашучының вафат булуы турында таныклык - махсус хәрби операциядә һәлак булган (вафат булган) катнашучысы булган гаилә әгъзалары өчен.

Гаризада кабул ителгән карар турында хәбәр итү ысулы күрсәтелә (шул исәптән почта адресы һәм (яисә) электрон почта адресы).

Документларның күчермәләрен гаилә әгъзасы һәр биткә шәхси имза кую юлы белән таныклый.

Документларның күчермәләрен тапшырганда, документларның төп нөсхәләре карап чыгу өчен күрсәтелә.

Гаилә әгъзасы гаризада күрсәтелгән белешмәләрнең дөреслеге һәм тулылыгы өчен Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплы.

7. Кергән документлар Сектор тарафыннан аларны тапшырган көнне үк теркәлә.

8. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе гаризаны теркәлгән көннән алып 10 (ун) эш көненнән дә артмаган вакытта карый.

9. Гаризаны карау йомгаклары буенча түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

каты ягулык (утын пүләннәре рәвешендә киселгән утын) белән тәэмин итү һәм илтү турында;

баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп каты, ягулык (утын пүләннәре рәвешендә киселгән утын) белән тәэмин итүдән һәм илтүдән баш тарту турында.

Күрсәтелгән карар гаилә әгъзасына язма хәбәрнамә рәвешендә гаризада күрсәтелгән ысул белән әлеге Тәртипнең 8 бүлегендә билгеләнгән гаризаны карау срогыннан да соңга калмыйча җибәрелә.

10. Каты ягулык (утын пүләннәре рәвешендә киселгән утын) белән тәэмин итүдән һәм илтүдән баш тарту өчен нигезләр:

әлеге Тәртипнең 4 бүлегендә күрсәтелгән затларның категориясе туры килмәү;

тапшырылган документларда дөрес булмаган яисә бозып күрсәтелгән мәгълүмат ачыклану;

мич белән җылытылмау;

документның текстын укырга һәм аның эчтәлеген бер мәгънәдә аңларга мөмкинлек бирми торган төзәтүләр, өстәп язылган яки сызылган сүзләр, килештерелмәгән башка төзәтмәләр, бозулар булган документлар тапшыру;

гаилә әгъзасы тарафыннан гаризаның кире алынуы;

әлеге Тәртипнең 6 бүлегендә күрсәтелгән документларның тулы булмаган пакетын тапшыру.

11. Баш тарту өчен нигез булган сәбәпләрне бетергәндә каты ягулык (утын пүләннәре рәвешендә киселгән утын) белән тәэмин итүгә һәм илтүгә бәйле өстәмә ярдәм чарасын күрсәтү өчен документлар әлеге Тәртип нигезендә Секторга яңадан тапшырылырга мөмкин.

12. Гаилә әгъзасы күрсәткән адрес буенча каты ягулыкны (утын пүләннәре рәвешендә киселгән утынны) илтү каты ягулык (утын пүләннәре рәвешендә киселгән утын) белән тәэмин итү һәм илтү турында карар кабул ителгән вакыттан алып 30 (утыз) календарь көн эчендә гамәлгә ашырыла.

1 нче кушымта

Татарстан Республикасы
Арча муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе
Р. М. Гатиятовка

Кемнән_________________________________
(гариза бирүченең ФИАи)

«___» ________________ елда туган
паспорт серисе______ №______________,
бирелгән _______________________________
_____________________________________,
(нинди органом тарафыннан кайчан бирелгән)

Теркәлү адресы:____________________________________
тел. _________________________________
электрон почта адресы:
_____________________________________

**ГАРИЗА**

Мин _______________ граждан ______________________________
(туганлык дәрәҗәсен күрсәтергә)

_____________________________________________________________________,
(махсус хәрби операциядә катнашучының ФИАи., туу датасын, теркәлү адресын, категориясен күрсәтергә)

____________________________________________________адресы буенча җылыту өчен 3 куб. метр күләмендә каты ягулык (утын пүләннәре рәвешендә киселгән утын) белән тәэмин итүне һәм илтүне оештыруны сорыйм.

Әлеге гариза белән үзем, гаиләм һәм мөлкәтем турында дөрес булмаган мәгълүматлар биргән өчен тулысынча җаваплы булуымны раслыйм.

Әлеге гариза белән раслыйм, миңа элек махсус хәрби операциядә катнашучының гаилә әгъзаларын каты ягулык белән тәэмин итү һәм илтү белән бәйле өстәмә ярдәм күрсәтелмәде. Кабул ителгән карар турында миңа шәхсән, почта, электрон почта аша хәбәр итүегезне сорыйм: _________________________________________________________________.
(электрон почта адресын күрсәтергә / кирәклесен ассызыкларга)

Кушымта:

| | |
|---|---|
| | |
| | |

| | |
|---|---|
| | |
| | |
| | |
| | |
| | |
| | |
| | |

Әлеге гаризада булган шәхси белешмәләрне эшкәртүгә, шул исәптән (чикләүсез) мәгълүмат алмашу гамәлләрен башкару өчен җыю, системалаштыру, туплау, саклау, төгәлләштерү (яңарту, үзгәртү), файдалану, өченче затларга тапшыруга, шәхси белешмәләрне шәхессезләндерүгә, блоклауга, шулай ук Россия Федерациясенең гамәлдәге законнарында каралган теләсә нинди башка гамәлләрне башкаруга ризалык бирәм.

Әлеге гаризадагы шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык әлеге ризалыкны кире алу турында гариза бирү датасына кадәр гамәлдә.

«___» __________20 ___ ел______________________ ________________

(ФИАи) (имза)